**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

13 нче ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча 2024 елның 13 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «сез 2025 елда үзара салым кертүгә һәр балигъ яшьтәгедән 1000 сум күләмендә ризамы? Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән кеше, I төркем инвалидлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту.

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 160 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 82 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 82 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы составына керүче Балтач авыл җирлегенең гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. 2025 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан тыш, 1000 сум

күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:: - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

4. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.:

- Балтач ав., Мәктәп ур., 1 йорт (административ бина);

- Балтач ав., Мәктәп ур., 2 йорт (Балтач мәдәният йорты), шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Балтач авыл җирлеге башлыгы: Д.И. Мөхәммәдуллин